| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|

| ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР |
|---|---|
| 2017 ел, 14 гыйнвар | № 7 |

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтага үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Җир өчен аренда түләве турында» 1995 ел, 9 февраль, 74 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2000 ел, 21 июнь, 436 нчы; 2006 ел, 27 апрель, 211 нче; 2006 ел, 15 июнь, 303 нче; 2006 ел, 17 июль, 366 нчы; 2008 ел, 25 июль, 536 нчы; 2009 ел, 30 март, 192 нче; 2009 ел, 25 май, 333 нче; 2009 ел, 24 декабрь, 879 нчы; 2011 ел, 23 май, 404 нче; 2011 ел, 21 декабрь, 1027 нче; 2012 ел, 06 февраль, 86 нчы; 2012 ел, 17 июль, 605 нче; 2012 ел, 20 декабрь, 1110 нчы; 2013 ел, 31 май, 367 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасы милкендәге һәм үзләренә карата дәүләт милке чикләнмәгән җир кишәрлекләре өчен аренда түләве күләмнәрен билгеләү тәртибе турындагы нигезләмәгә теркәлгән кушымтага түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

җир кишәрлегеннән файдалану төрен исәпкә ала торган төзәтү коэффициентлары исемлегенә түбәндәге эчтәлекле юллар өстәргә:

| | |
|---|---|
| «Аларны оештыру, төзү, эксплуатацияләү, төзекләндерү, модернизацияләү «Концессия килешүләре турында» 2005 ел, 21 июль, ФЗ-115 нче Федераль закон нигезендә төзелгән шартнамәләр, килешүләр буенча гамәлгә ашырыла торган гидротехника корылмалары өчен (су мохите йогынтысына дучар булган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул | 0,1 |

| | |
|---|---|
| исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмау өчен күздә тотылган корылмалар, шул исәптән буалар, суташлагыч, сутөшергеч һәм су чыгара торган корылмалар; насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзлар; судно күтәргечләр; су басудан, сусаклагычлар ярлары, елга юлларының ярлары һәм төбе җимерелүдән саклау өчен каралган корылмалар; киртәләү өчен корылмалар; дамбалар, ярларны ныгыту өчен корылмалар, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән; пирслар; техник су белән тәэмин итү корылмалары системалары) | |
| Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 25 пунктчасы яки «Концессия килешүләре турында» 2005 ел, 21 июль, ФЗ-115 нче Федераль закон нигезендә бирелгән җир кишәрлекләре белән чиктәш һәм Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 3 пунктчасы нигезендә бирелгән җир кишәрлекләрендә төзелгән объектлар өчен | 0,1 |
| Россия Федерациясе Җир кодексының $39^6$ статьясындагы 2 нче пунктның 25 пунктчасы нигезендә төзелгән аренда шартнамәләре буенча 2017 елның 1 гыйнварыннан соң үз акчасы һәм (яки) заем акчасы исәбеннән төзелә торган гидротехника корылмалары өчен (су мохите йогынтысына дучар булган, су ресурсларыннан файдалану һәм аларны саклау, суларның, шул исәптән сыек калдыклар белән пычранган суларның зарарлы йогынтысын булдырмау өчен күздә тотылган корылмалар, шул исәптән буалар, суташлагыч, сутөшергеч һәм су чыгара торган корылмалар; насос станцияләре; суднолар йөри торган шлюзлар; судно күтәргечләр; су басудан, сусаклагычлар ярлары, елга юлларының ярлары һәм төбе җимерелүдән саклау өчен каралган корылмалар; киртәләү өчен корылмалар; дамбалар, ярларны ныгыту өчен корылмалар, яр буйлары, шул исәптән аларда урнашкан төзекләндерү һәм коммерция инфраструктурасы объектлары белән; пирслар; техник су белән тәэмин итү корылмалары системалары) | 0,1». |

2. Бу карарның гамәле 2017 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков